**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2026 елның 24 феврале 261номер

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының урта һөнәри яисә югары белем бирү мәгариф оешмасында максатчан уку турында шартнамә төзүгә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрен сайлап алуны уздыру тәртибе турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 3760 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024елның 27 апрелендәге 555 номерлы карары нигезендә "Урта һөнәри һәм югары белемнең белем бирү программалары буенча максатчан уку турында" **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең урта һөнәри яисә югары белем бирү мәгариф оешмасында максатчан уку турында шартнамә төзүгә дәгъва кылучыларны сайлап алу комиссиясе составын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Солягин Артем Олегович | - Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе; |
| Хөсәенова Лия Илдус кызы | - "Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы мәгариф идарәсе" МКУ башлыгы, комиссия рәисе урынбасары; |
| Новикова Ольга Яковлевна | - "МКУ Мәгариф идарәсе" методисты, комиссия секретаре (килешү буенча); |
| Комиссия әгъзалары: | |

| | |
|---|---|
| Пучкова Татьяна Константиновна | - "Лаеш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ДКУ директоры (килешү буенча); |
| Германов Виталий Викторович | - Лаеш районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Яковлева Виктория Николаевна | - район Башкарма комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе; |
| Карсалов Алексей Петрович | - район Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы; |
| Николаев Ярослав Юрьевич | - "Лаеш үзәк район хастаханәсе" ДАССУ баш табибы (килешү буенча); |

**2.** 3 нче кушымтаның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Урта һөнәри һәм югары белемнең уку-укыту программалары буенча максатчан укыту турында" 2024елның 27 апрелендәге 555 номерлы карары, ("Урта һөнәри һәм югары белемнең белем бирү программалары буенча максатчан уку турында нигезләмә", "Федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән югары белемнең белем бирү программалары буенча максатчан уку-укытуга кабул итү квотасын билгеләү кагыйдәләре" белән бергә), Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Т. Гарифуллин